**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күңгәр авыл җирлеге Күшәр торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“23” ноябрь 2023 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Күшәр торак пунктында халык җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күшәр авылы территориясендә 2024 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Күшәр авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән контракт төзегән хәрби хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

- урам утларын яктырту максатыннан лампалар,автоматлар,стартер, таймерлар сатып алу һәм урнаштыру, хезмәтләр өчен түләү;

- авыл территориясен төзекләндерү (чүп үләннәрен чабу,чистарту),хезмәтләр өчен түләү.

- Октябрь һәм Х.Такташ урамыннарында урнашкан коеларны(4 ш.), Фрунзе урамындагы чишмәне(1 шт.) койма белән әйләндереп алу (төзелеш материаллары алу, транспорт чыгымнары һәм хезмәтләр өчен түләү).

Экономия ясалган очракта, Күңгәр авыл җирлеге башкарма комитетына халыктан җыелган акчаны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга рөхсәт итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Күшәр авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Күңгәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күшәр авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күңгәр авыл җирлеге башлыгы: Рәхимҗанова Г.И.